

Теш пастасы авыз куышлыгы гигиенасын саклауда топ рольне башкара. Моннан тыш, паста уртларнын сәламәтлегенә дә тәэсир итә. Шуна күрә аны дорес сайлау моһим. Теш пастасы сайлаганда нинди хаталар жибәрәбез һәм анын составында нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк? Бу хакта теш табибы Илья Антонов сойләгән, дип яза «Аргументы и факты».      Балалар һәм олкәннәр очен аерым теш пастасы сатып алырга кирәк. Моннан тыш, балалар очен теш пасталары 0-3 яшь, 3-6 яшь, 6-13 яшь категорияләренә бүленә. Балаларнын тешен олкәннәр очен паста белән чистарткан очракта, аларнын теш эмален бозу һәм уртларын ярсыту куркынычы бар. Шул ук вакытта, әйтик, 8 яшьлек баланын тешен чистарту очен, кечкенәрәк яшьтәге балалар очен паста кулланырга да ярамый. Бу очракта бераздан анын тешләре чистартылмаган пычрак катламы белән капланачак, чонки мондый пастанын составында абразив матдәләр житәрлек түгел.

Теш пастасынын составында шикәр булу-булмауга игътибар итәргә кирәк. Составта шикәр булырга тиеш түгел. Күпчелек заманча пасталарда ул юк, ләкин кайбер житештерүчеләр балалар очен пасталарга шикәр ости.

Шулай ук составта аллергия реакциясе китереп чыгара ала торган матдәләр булмавын да тикшерергә кирәк. Тагы пастанын нинди максат очен булуын карап алырга кирәк. Олкәннәр очен теш пасталары берничә торгә бүленә: дәвалый торган; агарта торган; абразивлы пасталар.

Дәвалый торган пасталарда абразив кисәкчәләр азрак һәм дәвалаучы компонентлар күбрәк. Антибактериаль пасталарда микроэлементлар азрак. Агартучы пасталарда исә эмальнен тосен үзгәртүче актив химик элементлар концентрациясе күбрәк. Абразивлы пасталарда эмаль ослешендәге пычрак катламын яхшырак чистарту очен каты гранулалар күбрәк була. Дәвалый торган паста сайлаганда башта табиб белән киңәшләшергә кирәк, чонки мондый пасталарны даими рәвештә кулланырга ярамый. Аларны гадәттә 1 айдан алып 3 айга кадәр кулланалар, аннары гади пастага күчеп торырга кирәк. Мондый паста кулланунны туктатып тормаган очракта, авыз куышлыгынын бактериаль фоны дару компонентларына ияләшә, һәм пастанын файдасы кими. Шулай ук инструкцияне игътибар белән укырга киңәш ителә. Мондый пасталарда дәвалау үзлеге тюбикны ачканнан сон ничә кон саклануы күрсәтелә. Кайбер очракларда бу 30 коннән дә күбрәк булмаска момкин.

Абразивлы паста сайлаганда каты кисәкчәләр һәм гранулаларнын күплегенә һәм зурлыгына игътибар итәргә кирәк. Гранулалар зуррак булган саен паста агрессиврак була. Эмаль кырылу күзәтелгән очракта, шунда ук пастаны кулланунны туктатырга һәм стоматологка морәҗәгать итәргә кирәк.

Агарта торган пасталар, гадәттә, тәмәке тартучы, кофе һәм теш эмаленен тосен үзгәртүче башка продуктлар кулланучы пациентларга киңәш ителә.

Агартучы компонентнын концентрациясе югарырак булган саен, авыз куышлыгынын лайлалы тышчасын пешерү куркынычы зуррак.

Белгеч, теш пастасын сайлаганда, стоматолог белән киңәшләшергә куша.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**